КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 ноябрь г.Казань № 1083

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 635 нче карары белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 635 нче карары белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасына (алга таба – Төбәк программасы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Төбәк программасы паспортында:

«Үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) объектлары саны» юлында «24» санын «26» санына алыштырырга;

«Елларга һәм чыганакларга бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Елларга һәм чыганакларга бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме</td>
<td>2019 – 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 12 201 598,1 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барлыгы</th><th colspan="3">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</th><th>бюджеттан тыш акча</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>3 311 821,50</td><td>352 799,50</td><td>1 504 040,00</td><td>1 454 982,00</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>2 382 626,00</td><td>360 962,00</td><td>1 538 838,00</td><td>482 826,00</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 502 417,30</td><td>285 459,30</td><td>1 216 958,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 302 993,30</td><td>239 205,30</td><td>1 019 770,00</td><td>44 018,00</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>1 564 470,00</td><td>297 250,00</td><td>1 267 220,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>2 137 270,00</td><td>406 080,00</td><td>1 731 190,00</td><td>0,00</td></tr>
<tr><td>Бар-лыгы</td><td>12 201 598,10</td><td>1 941 756,10</td><td>8 278 016,00</td><td>1 981 826,00</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td>
</tr>
</table>

«Төбәк программасы максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Төбәк программасы максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Төбәк программасы чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:<br>2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның күләмен 1 елга 0,06 куб. километрга кадәр киметергә, шул исәптән:<br>2019 ел – 1 елга 0,19 куб. километрга кадәр;<br>2020 ел – 1 елга 0,18 куб. километрга кадәр;<br>2021 ел – 1 елга 0,16 куб. километрга кадәр;<br>2022 ел – 1 елга 0,14 куб. километрга кадәр;<br>2023 ел – 1 елга 0,14 куб. километрга кадәр;<br>2024 ел – 1 елга 0,06 куб. километрга кадәр;<br>2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып |

| | |
|---|---|
| | төшерелә торган пычрак суларны агызуны киметүне тәэмин итә торган чистарту корылмалары егәрлеге 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр артуны тәэмин итәргә, шул исәптән:<br>2019 ел – 1 елга 0,0 куб. километрга кадәр;<br>2020 ел – 1 елга 0,01 куб. километрга кадәр;<br>2021 ел – 1 елга 0,03 куб. километрга кадәр;<br>2022 ел – 1 елга 0,05 куб. километрга кадәр;<br>2023 ел – 1 елга 0,05 куб. километрга кадәр;<br>2024 ел – 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр.<br>Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпләү бу Төбәк программасының VIII бүлегендә китерелде |

III бүлекнең икенче абзацында «Минзәлә муниципаль районы,» сүзләреннән соң «Түбән Кама муниципаль районы,» сүзләрен өстәргә;

IV бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## IV. Төбәк программасын тормышка ашыру өлкәсе тасвирнамәсе, экологик хәлне яхшырту чаралары тасвирламасы

Төбәк программасы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының « Үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программаларын әзерләү буенча методик тәкъдимнамәләрне раслау турында» 2019 елның 30 апрелендәге 254/пр номерлы боерыгы таләпләрен исәпкә алып эшләнде.

Су объектларының торышы дәүләтнең социаль, икътисадый һәм экологик иминлеген билгели торган өлешләрнең берсе булып тора.

Татарстан Республикасында коммуналь хуҗалык канализациясенең 86 чистарту корылмасы, 348 канализация насос станциясе эксплуатацияләнә.

Республикада эшли торган канализация чистарту корылмаларының билгеләнгән үткәрү сәләте тәүлегенә 1,73 млн.куб.метр тәшкил итә. Канализациянең чистарту корылмалары аша суларны үткәрү тәүлегенә 709,9 мең куб.метр тәшкил итә.

Агызыла торган суларны тулысынча биологик чистарта торган чистарту корылмалары Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Зеленодольск, Лениногорск, Чистай, Зәй, Тәтеш, Нурлат, Менделеевск шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы Урыссу поселогында файдаланыла.

Канализация челтәрләренең озынлыгы якынча 4,5 мең км тәшкил итә, шуларның 1,7 мең километры алмаштыруны таләп итә.

Татарстан Республикасында канализациянең гамәлдәге чистарту корылмалары торышын мониторинглау күрсәтүенчә, кайбер шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә үзәкләштерелгән су чыгару системалары объектларының тузу проценты югары, алар канәгатьләндерерлек итеп эшлими һәм, халык сәламәтлегенә куркыныч тудырып, су объектларына нормативларга туры килми торган агызыла торган суларны чыгаруны дәвам итәләр.

Чистарту корылмаларының күпчелеге реконструкцияләүне, агызыла торган суларны чистартып бетерү җайланмаларын урнаштыруны таләп итә. Тиешле дәрәҗәдә чистартылмаган агызыла торган суларны агызу сәбәпләренең берсе – агызыла торган суларны чистартуның искергән технологияләрен куллану, канализация хуҗалыгының төп фондлары физик яктан шактый тузган булу. Агызыла торган суларны чистартуның таләп ителә торган параметрларына ирешү өчен канализациянең чистарту корылмаларын модернизацияләргә һәм реконструкцияләргә кирәк.

Күп кенә авыл торак пунктларында үзәкләштерелгән су чыгару системасы юк.

Агызып төшерелә торган суларның сыйфатын норматив күрсәткечләргә җиткерү юлы белән экологик хәлне яхшырту максатларында, республикада 2017 – 2018 елларда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 61 су чыгару объекты төзелде (реконструкцияләнде) һәм капиталь ремонтланды, гомуми суммасы 317,6 млн.сум тәшкил итте.

Мәсьәләне сууткәргеч-канализация хуҗалыгы предприятиеләренең үз акчасы хисабына гына хәл итү мөмкин түгел, чөнки кирәкле чараларның бәясе шактый кыйммәт тора.

Татарстан Республикасында Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның күләме 1 ела 0,19 куб. километр тәшкил итә.

Бу мәсьәләне хәл итү максатларында, Төбәк программасына 26 чара кертелгән, аларны тормышка ашыру чистарту корылмалары егәрлеген 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Казан шәһәренең Ветеринария академиясе районындагы су объектларына яңгыр сулары канализациясе чыгарыла торган урыннарда агызып төшерелә торган өске суларны чистарту корылмаларын төзү. Бүгенге көндә су объектларын җир өстеннән агызып төшерелә торган сулар белән пычрату актуаль проблема булып тора, чөнки алар яңгыр сулары канализацияләре челтәрләре аша үтә һәм чистартылмыйча төшерелә. Чистарту корылмалары булмау сәбәпле, сулыклардагы су пробаларының бактериаль һәм санитария-химия күрсәткечләре буенча канәгатьләндерерлек булмау проценты югары булып кала. Казансу елгасына тискәре йогынты ясау чыганакларының берсе – ул Себер тракты урамында Казан шәһәренең Совет һәм Яңа Савин районнары территориясеннән 1000 мм диаметрлы торба буенча 59 гектардан артыграк мәйдан белән яңгыр сулары канализациясен агызу. Төзелеш проекты Идел елгасына антропоген йогынтыны киметергә мөмкинлек бирә торган заманча технологияләр куллануны күздә тота.

Казан шәһәренең канализация биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү, I, II, III этаплар. Проект җитештерүчәнлеге (реконструкциядән соң) – тәүлегенә 650 мең куб.метр. Канализация биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү Куйбышев сусаклагычы акваториясендә экологик иминлекне яхшырту һәм саклау зарурлыгына, пычраткыч матдәләр концентрациясен чистартылган агызыла торган суларда рөхсәт ителгән чыгаруларның билгеләнгән нормаларына кадәр җиткерү зарурлыгына бәйле булып тора. Реконструкция ясау шәһәрнең алга таба үсеше өчен кирәк. Аны ясаганнан соң корылмалар агызыла торган суларны шәһәрнең 250 меңнән артык кешесеннән өстәмә рәвештә кабул итә алачак. Яңа биологик чистарту корылмалары төзү, энергия сыйдырышлы

технологик җиһазны алыштыру, агызыла торган суларны чистарту нәтиҗәләрен расланган норматив-рөхсәт ителгән сулар чыгару таләпләрен үтәү һәм балык хуҗалыгы сулыкларының рөхсәт ителгән иң чик концентрациясе дәрәҗәсенә кадәр җиткерү, агызып төшерелә торган сулардан азот һәм фосфорны юкка чыгару өчен «нитри-денитрификация» технологиясен гамәлгә кертү күздә тотыла.

Казан шәһәрендәге Идел буе су алу җайланмасының юдыру һәм шлам суларын чистарту корылмаларын төзү. Объектның җитештерүчәнлеге – тәүлегенә 80 мең куб.метр юдыру суларын чистарту. Юдыру һәм шлам суларын чистарту корылмаларын төзү зарурлыгы агызыла торган суларны, алдан чистартмыйча, сулыкка чыгара торган су белән тәэмин итү системаларын эксплуатацияләүне тыя торган яңа законнар таләпләренә бәйле. Проектны тормышка ашыру чистартылмаган суны суүткәргеч чистарту корылмаларына бирүне киметергә һәм пычраткыч матдәләрне Идел елгасына чыгаруны туктатырга мөмкинлек бирәчәк. Проектта юдыру һәм шлам суларын чистарта торган яңа корылмалар төзү һәм гамәлдәгеләрен реконструкцияләү, юшкынны сусызландыру каралган. Объект төзүнең социаль-икътисадый нәтиҗәсе Идел елгасына антропоген йогынты ясауны киметүдә, шәһәрдә, шул исәптән су объектында экологик хәлне яхшыртуда чагыла.

Казан шәһәренең Авиатөзелеш районына караган Крутушка поселогының канализация чистарту корылмаларын реконструкцияләү. Җитештерүчәнлеге – тәүлегенә 800 куб.метр. Крутушка поселогының чистарту корылмаларына бара торган һәм агызыла торган суларның сыйфатын формалаштыручы төп (бердәнбер эре) абонент – ул шифаханә, аның агызыла торган сулары үзәкләштерелгән челтәрләргә бара торган агынты суларга карата куелган таләпләргә туры килми. Крутушка поселогының чистарту корылмаларында кулланыла торган биофильтрлардагы классик чистарту технологиясе «Крутушка шифаханәсе» акционерлар җәмгыятенең җитештерү агынты суларындагы үзенчәлекле пычраткычларны бетерү өчен билгеләнмәгән. Чистарту корылмаларын реконструкцияләү эшләрен башкарырга кирәк.

Яр Чаллы шәһәренең «Замелекесье» торак районында яңгыр сулары канализациясен төзү. Районда яңгыр сулары агымы һәм яңгыр сулары агымын чыгару оештырылмаган. Яңгыр сулары агымын оештыру җирнең рельефы буенча, канаулар ясап һәм юл астыннан суүткәргеч торбалар сузып, табигый рәвештә башкарыла. Яр Чаллы шәһәрендә яңгыр сулары канализацияләре челтәрләрен төзү яңгыр суларын җыюны һәм чистартуны оештырырга мөмкинлек бирәчәк.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кызыл Бор авылында биологик чистарту корылмаларын төзү. Хәзерге вакытта Красный Бор авылында 2 мең кеше яши. Элегрәк эксплуатацияләнгән чистарту корылмалары 2001 елда консервацияләнгән. Тузган хәлдә булганга күрә, аларны эксплуатацияләп булмый. Әгерҗе муниципаль районының Кызыл Бор авылында төзелә торган канализация чистарту корылмалары тәүлегенә 150 куб.метр күләмендә агызыла торган суларны кабул итүне тәэмин итәчәк.

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында чистарту корылмаларын төзү. Бүгенге көндә Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында 8,5 мең кеше яши. Эшли торган чистарту корылмалары агызып килә торган суларны норматив таләпләргә кадәр чистарта

алмый (механик чистарту стадиясе юк). Яңа чистарту корылмалары агызыла торган суларны тулы биологик һәм тирәнтен чистартып бетерә торган итеп проектлаштырылган.

Бөгелмә шәһәренең канализация чистарту корылмаларын реконструкцияләү. Җитештерүчәнлеге тәүлегенә 22 мең куб.метр булган гамәлдәге канализация чистарту корылмалары 1981 елдан бирле эксплуатацияләнә. Корылмаларда аэротенкның, беренчел һәм икенчел тондыру бассейннарының бетон конструкцияләрен ремонтларга, утырма чистарткычларны, утырма суырткычларны, ярым чумдырыла торган щитларны, шиберларны алыштырырга кирәк. Агызыла торган суларны зарарсызландыруның заманча ысулларын кулланышка кертергә кирәк.

Буа шәһәренең канализация биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү. Буа шәһәренең торак төзелеш корылмаларыннан агызыла торган сулар проект егәрлеге тәүлегенә 4,28 мең куб.метр булган биологик чистарту корылмаларына килә. Биологик чистарту корылмалары 1965 елда төзелгән. Биологик чистарту, агызыла торган суларны чистартып бетерү корылмаларының конструктив элементларына, утырманы сусызландыру корылмаларына, утырманы аэроблы стабильләштерү корылмаларына реконструкция ясарга кирәк. Ташландык суларның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау тимер юл станциясе поселогында һәм Биектау авылында биологик чистарту корылмаларын һәм тышкы су чыгару системаларын реконструкцияләү. Биектау тимер юл станциясе поселогында биологик чистарту корылмалары 1978 елда эксплуатацияләүгә тапшырылган. Хәзерге вакытта Биектау авылы янындагы агызыла торган сулар Биектау тимер юл станциясе поселогының чистарту корылмаларына бара. Чистарту корылмаларындагы агызыла һәм чыгарыла торган суларның сыйфаты норматив таләпләргә туры килми. Биектау авылы территориаль яктан киңәюгә һәм актив торак төзелешенә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау тимер юл станциясе поселогында һәм Биектау авылында биологик чистарту корылмаларын һәм тышкы су чыгару челтәрләрен реконструкцияләүгә ихтыяҗ туды. Проектта эшли торган чистарту корылмаларын киңәйтү күздә тотыла.

«Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасының һәм Алабуга шәһәренең районга караган агызыла торган көнкүреш һәм сәнәгать суларын чистарту корылмаларын реконструкцияләү. Хәзерге вакытта Алабуга шәһәрендә 77 меңнән артык кеше яши. 1991 елдан егәрлеге тәүлегенә 18 мең куб.метр булган һәм төзелеп бетмәгән канализация чистарту корылмалары файдаланыла. 2017 елгы техник хисап мәгълүматларыннан чыгып, җиһазның күбрәк өлеше тузган хәлдә яки эшләми. Мәсәлән, ком тотып калгыч җайланмасында өч каналдан икесе генә кулланыла. Ком тотып калгыч җайланмасыннан ком юдыргычның үткәргеч торбасы тузган, үткәргеч торбаның эшермәсе герметик рәвештә ябылмый. 8 беренчел тондыргыч бассейнның икесе эштә, икесе резервта, калган дүртесе төзелеп бетмәгән. Эксплуатацияләү чорында аэротенкларның бүлгесенә йөкләнешләр булу аркасында сыешлык корылмаларының дивар панельләре деформацияләнгән һәм алар өлешчә җимерелгән, панельара җөйләр аерылган. Аэротенкларга керү юлында затворлар тузган. Тондыргыч бассейннарның 3 нче каналы файдаланылмый.

Алабуга муниципаль районының Алабуга шәһәрендә канализация чистарту корылмалары тәүлегенә 19 500 куб.метр күләмендә агызыла торган суларны чистартуны тәэмин итәчәк.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәрендә, Поповка авыл җирлегендә чистарту корылмаларын төзү. Хәзерге вакытта Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлегендә 15 күпфатирлы торак йортта 650дән артык кеше яши. Шәхси сектор 1 600 торак йорттан тора, шуларның 165 йорты үзәк канализациягә тоташтырылган. Киләчәктә Поповка авыл җирлегендә яңа объектлар һәм торак йортлар төзү планлаштырыла. Иске чистарту корылмалары тулысынча җимерелү аркасында, агызыла торган сулар, тиешенчә чистартылмыйча, Ирнә елгасына чыгарыла. Проектта заманча технологияләр куллану күздә тотыла, бу эшне тотрыкландырырга һәм җиһазны эксплуатацияләү чыгымнарын шактый киметергә мөмкинлек бирәчәк. Бу – нитри-денитрификация процессында азотны, фосфорны бетерү, югары тизлекле ком фильтрларындагы агызыла торган суларны авыр матдәләрдән чистартып бетерү, хлорлау урынына чистартылган агызыла торган суларны ультрашәмәхә белән зарарсызландыру; болар хлорлы реагентлардан тулысынча баш тартырга мөмкинлек бирәчәк. Заманча эшне тотрыкландырырга һәм чистарту корылмаларын эксплуатацияләү чыгымнарын шактый киметергә мөмкинлек бирәчәк.

«Салават Күпере» торак районы өчен инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен төзү. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләре. 6 нчы этап: Васильево шәһәр тибындагы поселогының тәүлегенә 24 мең куб.метр җитештерүчәнлекле биологик чистарту корылмалары, шул исәптән беренче чиратта – тәүлегенә 12 мең куб.метрга кадәр. Тәүлегенә 3,5 мең куб.метр җитештерүчәнлекле гамәлдәге чистарту корылмалары агынтыларны норматив дәрәҗәдә чистартуны тәэмин итмиләр. Казан шәһәренең «Салават күпере» яңа микрорайонында су чыгаруны оештыру максатларында, шулай ук Васильево шәһәр тибындагы поселогы, «Залесный Сити», «Яңа Тура», «Радужный» торак төзелеш корылмалары йөкләнешен исәпкә алып, Васильево шәһәр тибындагы поселогының проект җитештерүчәнлеге тәүлегенә 3,5 мең куб.метр булган гамәлдәге биологик чистарту корылмаларын тәүлегенә 12 мең куб.метрга кадәр арттырырга кирәк.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Карамалы шәһәр тибындагы поселогында биологик чистарту корылмаларын төзү. Хәзерге вакытта Түбән Карамалы шәһәр тибындагы поселогында 7,5 мең кеше яши. Гамәлдәге чистарту корылмалары килә һәм агызыла торган суларны норматив таләпләргә кадәр чистартырга мөмкинлек бирми. Яңа чистарту корылмалары агызыла торган суларны тулы биологик һәм тирәнтен чистартып бетерә торган итеп проектлаштырылды.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәрендә биологик чистарту корылмаларының 2 нче чиратын төзү. Чистарту корылмалары 1986 елда төзелгән. Ташландык суларның сыйфаты начар булуга һәм җиһазларның тузуына бәйле рәвештә, иске корылмалар территориясендә яңа корылмалар төзү турында карар кабул ителде. 2018 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән тәүлегенә 400 куб.метрга чистарту корылмаларының 1 нче чиратын төзү эшләре башкарылды. Лаеш шәһәренең тәүлегенә 700 куб.метрга канализация

чистарту корылмалары комплексын төзеп бетерергә кирәк.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәрендәге биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү. Гамәлдәге 34 км озынлыктагы су чыгару челтәрләре Минзәлә шәһәренең 60 процент халкына хезмәт күрсәтә. Биологик чистарту корылмалары җиһазлары югары дәрәҗәдә тузган булуы белән характерлана. Агызыла торган суларны чистарту сыйфатының рөхсәт ителә торган нормалардан даими артып китүе күзәтелә.

Минзәлә муниципаль районының Юртово поселогында биологик чистарту корылмаларын төзү. Хәзерге вакытта Юртау поселогы абонентларының агызыла торган сулары җыеп бара торган сыешлыкка җыела һәм чистартылмыйча чыгарыла. Җитештерүчәнлеге тәүлегенә 75 куб.метрлы чистарту корылмаларын төзү зарури.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының шәһәр тибындагы Кама Аланы поселогында биологик чистарту корылмаларын төзү. Чистарту корылмалары физик һәм мораль яктан искергән, аларның тузганлыгы 95 процент тәшкил итә, шуңа күрә агызыла торган суларны чистарту сыйфаты заманча экологик таләпләргә туры килми. Чистартылган агынтылар Куйбышев сусаклагычының югары категорияле балык хуҗалыгы сулыгы булган Кама участогына чыгарыла. Шуның аркасында әлеге сулыкка чыгарыла торган агынтыларга карата аларны чистартуның сыйфаты буенча югары таләпләр куела. Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогында торак төзелешнең агынты сулары 12 км озынлыктагы басымлы коллекторлар буенча өч канализация насос станциясе аша 1988 елда төзелгән тәүлегенә 17 мең куб.метр проект егәрлекле канализация чистарту корылмаларына чыгарыла. Корылмаларның поселоктан шактый ерак булуы Татарстан АЭСе төзелеше нәтиҗәсендә поселок һәм сәнәгать мәйданчыклары үсешенә бәйле булган. Хәзерге вакытта корылмаларга факттагы йөкләнеш 15 процент тәшкил итә. Җиһаз күп энергия сыйдырышлы һәм нәтиҗәсез булып тора, кискен хәлдә тузган, агызыла торган суларны чистарту сыйфаты заманча экологик таләпләргә туры килми. Экологик һәм техник проблемаларны иң оптималь хәл итү – ул заманча чистарту корылмаларын төзү варианты.

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авылында биологик чистарту корылмаларын төзү. Гамәлдәге чистарту корылмалары корычтан ясалган, хәзерге вакытта алар тулысынча тузган. Яңа канализация чистарту корылмаларын төзергә кирәк.

Тәтеш шәһәрендә яңгыр сулары канализациясен булдыру. Районда яңгыр сулары агымы һәм яңгыр сулары агымын чыгару оештырылмаган. Яңгыр сулары агымын оештыру җирнең рельефы буенча, канаулар ясап һәм юл астыннан суүткәргеч торбалар сузып, табигый рәвештә башкарыла. Тәтеш шәһәрендә яңгыр сулары канализацияләре челтәрләрен төзү яңгыр суларын җыюны һәм чистартуны оештырырга мөмкинлек бирәчәк. Тәтеш муниципаль районының Тәтеш шәһәрендәге яңгыр сулары канализациясе челтәрләре яңгыр суларын тулы күләмдә кабул итүне һәм чистартуны тәэмин итәчәк.

Төбәк программасы чаралары исемлеге «Иделне савыктыру» федераль проекты паспорты белән билгеләнгән максатчан күрсәткечкә – пычрак агызыла торган суларны Идел елгасына чыгару 1 елга 0,06 куб. километрга ирешү өчен җитәрлек.»;

V бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Төбәк программасының төп максаты һәм бурычлары,
көтелә торган соңгы нәтиҗәләрне тасвирлау,
аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Төбәк программасының максаты – Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның өлешен өч тапкырга киметү.

Төп максатка ирешү өчен түбәндәге өстенлекле бурычларны комплекслы, системалы һәм максатчан хәл итәргә кирәк:

су чыгару һәм агызыла торган суларны чистарту секторында аның эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә һәм ышанычлылыгына юнәлдерелгән коммуналь инфраструктура системаларын үстерү;

су чыгару һәм агызыла торган суларны чистарту секторына озак вакытка исәпләнгән шәхси инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

хуҗалыкны эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганаклары булган сулыкларга норматив кебек булмаган чистартылган агызыла торган суларны агызу күләмнәрен киметү.

2019 – 2024 елларда Төбәк программасының максатына ирешү һәм бурычларын үтәү өчен үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) чаралары тормышка ашырылачак.

Төбәк программасы чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларның күләмен 1 елга 0,06 куб. километрга кадәр киметергә, шул исәптән:

2019 ел – 1 елга 0,19 куб. километрга кадәр;

2020 ел – 1 елга 0,18 куб. километрга кадәр;

2021 ел – 1 елга 0,16 куб. километрга кадәр;

2022 ел – 1 елга 0,14 куб. километрга кадәр;

2023 ел – 1 елга 0,14 куб. километрга кадәр;

2024 ел – 1 елга 0,06 куб. километрга кадәр;

2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларны агызуны киметүне тәэмин итә торган чистарту корылмалары егәрлеге 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр артуны тәэмин итәргә, шул исәптән:

2019 ел – 1 елга 0,0 куб. километрга кадәр;

2020 ел – 1 елга 0,01 куб. километрга кадәр;

2021 ел – 1 елга 0,03 куб. километрга кадәр;

2022 ел – 1 елга 0,05 куб. километрга кадәр;

2023 ел – 1 елга 0,05 куб. километрга кадәр;

2024 ел – 1 елга 0,13 куб. километрга кадәр.»;

VI бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI. Төбәк программасының ресурслар белән тәэмин ителеше

Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 12 201 598,10 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлыгы | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | бюджеттан тыш акча |
| 2019 | 3 311 821,50 | 352 799,50 | 1 504 040,00 | 1 454 982,00 |
| 2020 | 2 382 626,00 | 360 962,00 | 1 538 838,00 | 482 826,00 |
| 2021 | 1 502 417,30 | 285 459,30 | 1 216 958,00 | 0,00 |
| 2022 | 1 302 993,30 | 239 205,30 | 1 019 770,00 | 44 018,00 |
| 2023 | 1 564 470,00 | 297 250,00 | 1 267 220,00 | 0,00 |
| 2024 | 2 137 270,00 | 406 080,00 | 1 731 190,00 | 0,00 |
| Барлыгы | 12 201 598,10 | 1 941 756,10 | 8 278 016,00 | 1 981 826,00 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VIII. Федераль бюджеттан инвестицияләрнең бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү

| Рейтингтагы позициясе | Объектның исеме | Федераль бюджеттан инвестицияләр күләме, мең сум | Объекттан агызып чыгарыла торган пычрак сулар күләмен киметүнең план буенча күрсәткече, 1 тәүлеккә мең.куб.метр | Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткеченең мәгънәсе, сум/куб.метр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Яр Чаллы шәһәре, «Замелекесье» торак районы, яңгыр сулары канализациясе | 169 481,070 | 60,480 | 2 802,266 |
| 2. | Бөгелмә шәһәренең канализация чистарту корылмаларын | 138 361,043 | 22,204 | 6 231,357 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | реконструкцияләү | | | |
| 3. | Казан шәһәренең канализация биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү (шул исәптән:<br>Казан шәһәренең канализация биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү, 1 нче этап;<br>Казан шәһәренең канализация биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү,<br>2 нче этап;<br>Казан шәһәренең канализация биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү,<br>3 нче этап) | 3 330 476,440 | 393,464 | 8 464,501 |
| 4. | Казан шәһәрендәге Идел буе су алу җайланмасының юдыру һәм шлам суларын чистарту корылмаларын төзү | 916 154,800 | 80,000 | 11 451,935 |
| 5. | Казан шәһәренең Ветеринария академиясе районындагы су объектларына яңгыр сулары канализациясе чыгарыла торган урыннарда агызып төшерелә торган өске суларны чистарту корылмаларын төзү | 74 044,820 | 2,592 | 28 566,674 |
| 6. | Тәтеш шәһәрендә яңгыр сулары канализациясен булдыру | 88 155,630 | 3,024 | 29 151,994 |
| 7. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авылында биологик чистарту корылмаларын төзү | 72 900,000 | 1,500 | 48 600,000 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 8. | Буа шәһәренең канализация биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү | 149 040,000 | 2,100 | 70 971,429 |
| 9. | ««Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасының һәм Алабуга шәһәренең районга караган агызыла торган көнкүреш һәм сәнәгать суларын чистарту корылмаларын реконструкцияләү (шул исәптән: «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы һәм Алабуга шәһәренең агызыла торган көнкүреш һәм сәнәгать суларының район чистарту корылмаларын реконструкцияләү. I этап; «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы һәм Алабуга шәһәренең агызыла торган көнкүреш һәм сәнәгать суларының район чистарту корылмаларын реконструкцияләү. II этап) | 1 158 172,594 | 14,500 | 79 873,972 |
| 10. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Питрәч авылында биологик чистарту корылмаларын төзү | 121 500,000 | 1,100 | 110 454,545 |
| 11. | Татарстан Республикасы, Зәй муниципаль районы, Зәй шәһәренең, Поповка авыл җирлегенең чистарту корылмаларын төзү | 71 168,210 | 0,600 | 118 613,683 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 12. | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында чистарту корылмаларын төзү | 120 142,160 | 1,000 | 120 142,160 |
| 13. | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау тимер юл станциясе поселогында биологик чистарту корылмаларын һәм Биектау авылында тышкы су чыгару системаларын төзү | 243 000,000 | 2,000 | 121 500,000 |
| 14. | Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәрендә биологик чистарту корылмаларын реконструкцияләү | 307 803,787 | 2,000 | 153 901,894 |
| 15. | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәрендә биологик чистарту корылмала-рының икенче линиясен төзү | 69 417,000 | 0,450 | 154 260,000 |
| 16. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогында биологик чистарту корылмаларын төзү | 162 753,417 | 1,000 | 162 753,417 |
| 17. | Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының шәһәр тибындагы Кама Аланы поселогында биологик чистарту корылмаларын төзү | 283 500,000 | 1,300 | 218 076,923 |
| 18. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кызыл Бор авылында биологик чистарту корылмаларын | 43 366,140 | 0,150 | 289 107,600 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | төзү | | | |
| 19. | Минзәлә муниципаль районының Юртау поселогында биологик чистарту корылмаларын төзү | 24 300,000 | 0,075 | 324 000,000 |
| 20. | «Салават Күпере» торак районы өчен инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләрен төзү. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәрләре. 6 нчы этап: Васильево шәһәр тибындагы поселогының тәүлегенә 32 мең куб.метрга кадәр җитештерүчәнлекле биологик чистарту корылмалары, шул исәптән: беренче чират – 12 мең куб.метрга кадәр, икенче чират – тәүлегенә 32 мең куб.метрга кадәр | 651 658,889 | 2,000 | 325 829,445 |
| 21. | Казан шәһәренең Авиатөзелеш районына караган Крутушка торак пунктының канализация чистарту корылмаларын реконструкцияләү | 82 620,000 | 0,140 | 590 142,857 |
| | Барлыгы | 8 278 016,000 | 591,679 | 13 990,721 |

Чараларны тормышка ашыру чираты проект-смета документларының булуын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының проект-смета документларын эшләүгә акча бүлеп бирү турындагы боерыгының булуын һәм һәр елга аны тормышка ашыру өчен төбәк программасының максатчан күрсәткечен үтәү кирәклеген исәпкә алып билгеләнде.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Перспектив технологияләрне куллануга күчү

Канализация чистарту корылмаларының тагы да нәтиҗәлерәк эшләве өчен Төбәк программасында каралган үзәкләштерелгән су бүлү системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча чаралар ИТС 10-2015 белешмәлегенә кертелгән иң яхшы уңайлы технологияләрне кулланып гамәлгә ашырылырга тиеш.»;

Төбәк программасына теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Төбәк программасына теркәлгән 2 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Төбәк программасына теркәлгән 3 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Төбәк программасына теркәлгән 4 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

Төбәк программасына теркәлгән 5 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин